# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Бәрлебаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

13 нче ноябрь 2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 нче ноябрендә 10 сәгатьтә, 2020 елның 13 нче ноябрендә 09 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бермең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- Бәрлебаш авылында чүплекләрне чистарту(килешү буенча эш өчен түләү);
- Бәрлебаш авылында буаны чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
-Бәрлебаш авылында материаллар сатып алып су челтәрләрен ремонтлау(килешү буенча эш өчен түләү);
- Бәрлебаш авылында су башнясын лицензияләү буенча түләү (су анализы һәм башка документлар);
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- Бәрлебаш авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Бәрлебаш авылында җәйге чорда үлән чабу.»

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 135 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -82, бу 61 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 82 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең Бәрлебаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип таныргa.

2.«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 1000 (бермең) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Бәрлебаш авылында чүплекләрне чистарту(килешү буенча эш өчен түләү);
- Бәрлебаш авылында буаны чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
-Бәрлебаш авылында материаллар сатып алып су челтәрләрен ремонтлау(килешү буенча эш өчен түләү);
- Бәрлебаш авылында су башнясын лицензияләү буенча түләү (су анализы һәм башка документлар);
- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- Бәрлебаш авылында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Бәрлебаш авылында җәйге чорда үлән чабу.»

3. Әлеге карарны мәгъүлүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгъүлүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Ябалак авыл җирлеге Башлыгы М.Ф.Гыйзәтуллина